СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР
20.11.2018　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№4-36

2018 елның 18 ноябрендә җирле референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 апрелендәге № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча:
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек- Ерыкса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
**- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:**
- Яңа Комазан т.п. Сахалин ур., Г. Тукай ур., Кооператив ур., Көек - Ерыкса авылы-Гагарин ур., Наратлы ур.; Зур Шыя авылы-Давыдов ур.; Гришкино авылы-Кызыл Байрак урамы; Иске Черкас авылы-Кояшлы урамы; Малмыжка авылы-Гагарин ур.
- Көек-Ерыкса авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.
«ӘЙЕ»　　　　　　　　　　　　　　　　　«ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек- Ерыкса авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:
1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 909 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Көек-Ерыкса
авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе Ф.Р.Шәйхетдинов